

ISSN 0868-4545

Салават күпере





Әбием сандыгыннан

Һәй бу әбиләрнең сандыгынданиләр генә юк! Яртысы такмак-такмаза, үртәвечләр белән тулган. Әлбәттә, уеннар да бар. Шуларның берсе **«Әбәк»** дип атала.

Балалар бер төркем булып басалар. Шунда бер бала: «Әбәк-чәбәк, килеп юат!» — дип иптәшләренең берсенә сугып китә. Шулай дигәч, һәммәсе «әбәк» бирелгән бала яныннан читкә йөгерәләр. Куучы аларның кайсын да булса тотып, «әбәк»не бирергә тырыша. Әбәк бирелгән бала тагын үз чиратында балаларны куа башлый.

Уен шул рәвешчә дәвам итә.





Кызыклы арифметика



Бүре үзенең туган көненә 3 дуңгыз баласы, 6 кәҗә бәтие һәм Кызыл Калфак чакырган. Туган көненә бүре ничә кунак чакырган?



8 һәм 3 дигән ике сан яшәгән. Алар үзләре белән букча йөрткәннәр. Бер-бер куркыныч килеп чыкса, шул букчага сикереп менеп качалар икән. Букча эчендә икесе кушылып бер санга әвереләләр икән. 8 һәм 3 кушылгандагы санны табыгыз.

5 әби автобуска утырган. Аларның 2се билет сатып алган, калганнары: «Минеке бар»,— дигән. Чынлыкта 1 әбинең генә билеты булган.

Ничә әби «куян» булып барган?



Рәссам Светлана ПРИВИНА

БЫЛБЫЛ

Узган елның октябрь аенда башкалабыз Казанда «Иделем акчарлагы» дигән бәйгегә (оештыручылары – «Идел» яшьләр үзәге һәм Татарстан Язучылар берлеге) йомгак ясалды. Йомгаклау тантанасына әлеге бәйгедә катнашкан бик күп яшь иҗатчылар җыелды. Ошбу сәхифәдә шигырь-хикәяләре аеруча игътибарга лаек булган ике укучының иҗатыннан үрнәкләр тәкъдим итәбез.



Татар юрганы

Татарның үз җаны бар.
Татарның – үз вөҗданы.
Татарның үз каны бар.
Татарның бар үз даны!

Беркем моны үзгәрталмас,
Беркем дә кире какмас:
Юрганы кыска булса да,
Һәрчак булыр ул атлас.

Раилә ГАРИЕВА.
Саба, Тенеки.

Дуслар

«Сак булыгыз! Усал эт!» дигән язулы такта кадакланган койманы һәркем урап узарга тырыша иде. Әллә шушы язулы такта, әллә зур, йонлач этнең өрүе чынлап та өркетте инде – берәү дә койма янына якын килергә батырчылык итмәде.

Көннәрдән беркөнне биредә әллә каян гына нәни малай пәйда булды. Ул, кеше-кара юклыктан файдаланып, койманың каерылган тактасын читкә авыштырды да эчкә узды.

Күпмедер вакыттан соң малай, берни булмагандай, ялт итеп килеп тә чыкты һәм йөгереп китеп барды.

Бераздан ул янә койма буенда иде инде. Кочагында – уенчыклар!

Малай белән эт көне буе бергә уйнадылар. Кызык табып, малай йонлач дустының өстенә үк менеп атланды. Ни хикмәт, усал эттән шүрләмәде ул. «Йорт сакчысы» да малайны рәнҗетергә кыймады...

Аларның берсе дә укый белми иде.

Лилия ЗАКИРОВА.
Буа, Кайбыч.

Рәссам Светлана ИБРАҺИМОВА





Нәкыйп КАШТАН

Төнлә кояш чыкса...

Хикәя

Алия әкиятләр укырга һәм телевизордан цирк карарга ярата. Иң яраткан әкияте – Алып Батыр турында. Алып Батырның озын буен, дәү гәүдәсен күз алдына китерергә тырыша ул. «Чабатасына кергән комны каккач, тау кадәрле тау калыккан икән, Алып үзе нинди булды икән соң?» – дип аптырый Алия. – Башы болытларга тигәндер дә тигәндер инде!»

Ә циркта Алиянең иң яратып караганы – һавага туп чөеп уйнаучы клоуннар. Тупны җиргә төшермичә ничек шулай бер кулдан икенче кулга чөеп өлгерәләр икән алар?! Кулларына күз иярми, туплар гүя бер-берсен куышып уйный...

Тагын бер яраткан әйбере бар әле Алиянең: кичләрен кояш баеганын озаклап күзәтә ул. Кояш туп булып алсу шәфәкъкә акрын гына тәгәрәп төшә дә күздән югала. Шул чакта каршы офыкта зур булып Ай калка. Айның тәгәри-тәгәри өй каршындагы тупыл агачлары башына ук килеп җиткәнен дә көтәр иде Алия, әмма әбисе ашыктыра башлый шул. «Әйдә



Рәссам Илдар НӘФИЕВ



инде, кызым, керик, – ди. – Миңа намаз укырга, сиңа йокларга вакыт җитте», – ди...

...Бүген Алия төш күрде. Төшләрне йоклаган саен күрә ул. Әмма бу төше матурлыгы, башка төшләргә охшамавы белән аерылып тора иде. Төшендә ул Алып Батыр кебек зур гәүдәле клоунны күрде. Юк, юк, клоун булып киенгән Алып Батырны күрде Алия. Беләсезме, Алып Батыр нишләде: бер кулына Кояшны, икенче кулына Айны алып, туп итеп чөеп уйнады. Кояшны чөйде – көн булды, Айны чөйде – төн булды.

Иртән уянгач, Алия гаҗәеп төшен әбисенә сөйләде. Сүзен тәмамлап өстәп тә куйды:

– Хәзер, әбием, Ай белән Кояшның ни өчен күктә бергә йөрмәгәнен беләм инде, – диде. – Алып Батыр цирктагы кебек итеп чөеп уйный аларны. Беләсеңме, әбием... – Алия тынып калды. Күзләрендә курку шәүләсе чагылды. – Алып Батыр тупларын бутап чөя башласа, нәрсә булыр? Төнлә кояш чыкса, нишләрбез?..

Әбисе, елмаеп, оныгының аркасыннан сөйде:

– Курыкма, кызым. Алып Батыр аларны Ходай әмере белән чөя. Шуңа күрә бер дә ялгышмас... – диде.

Рашат НИЗАМИ шигырьләре

Сабыйчак иртәсе

Сабыйчакның кышкы иртәсе,
Күңелдән юк шуның китәсе,—
Йоклап яткан җирдән тәнемә
Юрган аша җылы бәреләә.

Юрганымны ачам уянып:
Өйнең эче балкый нурланып,
Әнкәй мичтән ипи алган ич,
Ак җәймәгә тезеп салган ич!

...Бураннарга хәтле сөенгән —
Тәрәзәмә килеп сыенган!





Урам чатында

Кулымда — кызыл шар,
Урамнар миңа тар.
Машина... машина...
Һәркайсы ашыга.

Сары шар кулымда,
Ни хикмәт юлымда?
Ничәмә машина
Тукталды каршымда?

Кулымда — яшел шар,
Әйдә, дим, алга бар.
Юл бирә «Жигули»,
«Шевроле», «КамАЗ»лар.

Сизгәнсең: мин шулай
Хыялый бер бала.
Өч төстә, шар булып,
Каршымда
С В ЕТ О Ф О Р елмая!

Йоклый кырда кибәннәр

Белмим, безнең басуларга
Каян килеп чыккан ул, —
Тау кадәрле динозавр!
Башын көрткә тыккан ул.

Туңып калган гәүдәсенә
Карлы бозлар эленгән.
Әллә кунакка килгәнме
Туң гасырлар иленнән?

Кояш астында җылынгач,
Кыймылдап алыр кебек.
Койрык сугып, кар диңгезен
Урталай ярыр кебек.

Иң өстемдә — агач мылтык...
Кышның якты көнендә
Батыраеп йөрим шулай
Динозавр өнендә.



Куркынычмы?

Алдашмыймын, чын әгәр:
Гәүдәсе — кибән кадәр!

Башын-күзен уйнатып,
Килә урам буйлатып.

Сарбайны да өркетте,
Каенны дер селкетте.

Тояклары «тып» та «тып»...
Булмас моны туктатып.

Маңгаенда — зу-ур мөгез,
Әйе, бу усал үгез!

Кодрәте — таң калырлык,
Кибетне аударырлык.

Юк, кибеткә кермәде,
Конфет сорап йөрмәде.

Койрык очын суктырып,
Өскә килә туп-туры!

Куркынычмы? Куркыныч!
Ә син, дустым, бул тыныч.

Минем белән уйна, көл:
Кулымда бит... бинокль.

Якынайтып үгезне,
Сынап карый ул безне!

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Балалар бакчасы

Кадерле балалар!

Безнең «Сыбызгы» үзгәрергә уйлады. Ул хәзер «Салават күпере»нең эчке битләрендә булачак.

«Сыбызгы» дигән исеме элеккечә калса да, бу хәзер яңа сәхифә. Яңа «Сыбызгы» сәхифәсе балалар бакчасындагы балаларны ярата. Шуңа күрә ул икенче төрле: «Сыбызгы» балалар бакчасында» дип тә атала.*

** Безнең һәр яңалыкка мөкиббән китеп, яратып, үз итеп һәм үзләре дә сизмичә үзләштерергә маһир татар журналистлары игътибарына: без «Балалар бакчасы» урынына киләчәктә яңа сәхифә уйлап табуга ук, әлеге сәхифәне сез дә рәхәтләнеп файдаланырсыз... аннары.*

Редакция.



Кыш көне урамда

Безнең балалар бакчасына бик күп балалар йөри. Мәсәлән, кайбер балаларның исемнәре: ***Азат, Булат, Айрат, Миләүшә, Гөлназ, Дамир…*** (Үзегезнең бакчадагы балаларның исемнәрен санап чыгыгыз).

Бирем:

Тәрбияче апа балаларга башларына, кулларына кияргә кушкан һәм шарфларыгызны да бәйләгез, дигән. Азат, Миләүшә, Дамир апаларының сүзләрен тыңлаганнар. Булат бияләен кияргә оныткан, Гөлназ муенына шарф салмаган, Айрат исә бияләен бер кулына гына кигән.

Рәсемнәр янына балаларның исемнәрен языгыз.

Рәссам Алла АЙСИНА







Ошбу сәхифәдәге рәсемнәрнең авторлары — Казандагы 5 нче татар гимназиясе һәм 26 нчы мәктәп укучылары (рәсем укытучысы — Г.М.Гайнетдинова).



Марат САФИН.



Алсу ХӘМИДУЛЛИНА.




Эльвира ХӘЙРЕТДИНОВА.



Азат ГАБДРАХМАНОВ.



Алмаз ХАММАТОВ.


Ләйлә, 8 яшь

— Нинди гөлләр?! Мин — нинди гөл?
Таныдыгызмы мине?! —
Гөлләр арасында үскән
Ләйлә-гөл булам инде.

Тукай, Биклән


Айгөл, 5 яшь
Резеда, 3 ай

— Куян алдына утыр, — дип
Айгөл апам өйрәтә...
Куян абый белән бергә
Төштек әле сурәткә.

Түбән Кама.




Илвир, 5 яшь

Шигырь сөйләп, җырлап аргач,
Килә биеп аласым...
Минем кебек була инде
Чып-чын татар баласы!

Әтнә, Күәм.


Булат, 10 ай

— Бер чиләк помидор җыйдым
Нәни кулларым белән.
Горурлансын әти-әни
Уңган уллары белән!

Арча, Ашытбаш.



Беренче җинаять

Туган туганын үтерде — коточкыч хәл!

Җирдә беренче кан коелды...

Кабил туганы Һабилне үтергәненә үкенде үкенүен, ләкин соң иде инде. Туганын югалту кайгысыннан ул үз-үзен кая куярга белмәде...

Әтиләре Адәмнең күңелен борчу биләп алды. Ул бөтен җирдән Һабилне эзләде. Ләкин таба алмады. Бераздан Адәм барысыннан да хәбәрдар булды. Кайгыдан аның йөрәге сыктады, гәүдәсе бөкрәйде, теле сөйләшмәс хәлгә килде...

Бу вакытта Кабил туганы Һабилнең үле гәүдәсен кая куярга белмәүдән гаҗиз иде.

Әмма Аллаһның һәрчак мәрхәмәтле булуын онытмыйк. Ул Кабилга бик каты сабак бирде: Аллаһ Кабил тарафына ике карга җибәрде. Каргалар бер-берсе белән сугыша башладылар, сугыша торгач, берсе икенчесен үтерде. Үтерүче карга томшыгы белән җирдә чокыр казыды һәм үлгән нәселдәшен шунда күмеп куйды. Кошның шулай кешене өйрәтүенә шаккатты Кабил.

Ул Һабилне үтергәненә бик нык үкенде. Үзенә бернинди файда булмасын да аңлады. Ләкин... соң иде шул инде, соң иде.

Гарәпчәдән **Алсу ХАСАВНЕХ** тәрҗемәсе.

Рәссам Булат ГЫЙЛЬВАНОВ







Зөлфия ВАККАЗОВА

Кышкы чәчәкләр

Әкият

Айдар үзе машиналар рәсемен ясарга ярата. Һәм кыш көне тәрәзәгә караган саен бик аптырый. Кыш бабай көнне суыткан саен пыялаларны гел чәчәкләр белән генә бизи... Чәчәкләр урынына берәр машина-мазар да төшерми ичмаса! Вәт кызык та булыр иде соң! Юк бит, һаман чәчәкләр дә чәчәкләр генә.

Айдар әлеге үпкәсен әбисенә дә әйтте. Ә әбисенең Кыш бабайга бернинди дә үпкәсе юк иде. Ул оныгына гаҗәп кызык әкият сөйләде.

Борын-борын заманда... Кыскасы, бер гаиләдә абыйлы-сеңелле ике туган яшәгән. Абый кеше үзе тапкыр, кыю, үзе нечкә күңелле малай икән. Кызчык исә бик шат, сөйкемле бала булган. Менә шул кызчык Яңа ел алдыннан, нәкъ Кыш бабай килер вакыт җиткәч кенә хасталана башлаган ди. Малай бертуган сеңлесен үлеп ярата бит инде. Бу хәлгә ул бик кайгырган, борчылган. Кыш бабай ишек шакыганчы сеңлесен тизрәк савыктырасы килгән. Тик... ничекләр итеп?.. Шулай баш вата торгач, сеңлесенең чәчәкләр яратуы исенә төшкән! Әйе, чәчәкләргә гашыйк ди шул сеңлесе. Чәчәкләр күрсә, үзе дә алар янында күбәләккә әйләнеп китә икән ди балакай! Кыш көне, бигрәк тә авыл җирендә, чәчәк бәйләмен кайлардан табасың инде?! Шулай аптырап утырган җиреннән малайның күзе кинәт тәрәзәгә төшә. Ә анда Кыш бабай матур-матур бизәкләр, чәчәкләр төшереп куйган икән!..

Абый кеше атылып урамга чыккан. Тәрәзәнең тышкы ягында да шул ук гаҗәп гүзәл чәчәкләр күргән. Шуннан соң малай чытырдатып күзләрен йомган һәм аларның тере чәчәкләргә әверелүен теләгән ди! Һай, шул чакта гаҗәп бер могҗиза булуын үз күзләрегез белән күрсәгез икән сез! Күзен ачып җибәрсә, кулында бер бәйләм аллы-гөлле чәчәк ди! Кыш бабай бу чәчәкләрне аңа тәрәзә пыяласыннан алып биргән. Әлбәттә, тылсымлы таягы ярдәмендә инде!.. Кызчык та чәчәкләр исеннән терелеп аягына баскан.

«Менә шулай, Айдар улым, – дигән әбисе. – Әгәр күңелең изгелектә булса, җир йөзендә могҗиза туып торачак!»

Шуннан бирле Кыш бабай – Суык бабай тәрәзә пыялаларын гел чәчәкләр белән бизәкләп йөри, ди.

Әлбәттә, кешеләрнең күңелен күрер өчен инде...

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Бик курчак

Алсуның 5 курчагы бар. Исемнәре: Айгөл, Зөһрә, Зилә, Айсылу һәм Сөмбел.


Айгөл бик шат, көләч. Алсуның сүзен тыңлый. Бер дә киреләнми. **Зөһрә** уйчан, җитди. Китап укырга ярата.

Зилә кап-кара күзле, кара чәчле. Авызы гел ерык булыр.

Айсылу үпкәчел, киребеткән курчак. Ул Алсу апасы әйткәнне бер дә тыңларга яратмый. Авызлары турсайган.

Сөмбел шапшаграк курчак. Чәчләре дә тузган. Алсу апасы чәчен тарый башлауга еларга гына тора.

Рәсемдәге курчаклар арасыннан Айгөлне, Зөһрәне, Зиләне һәм Айсылуны эзләп тап. Яннарына исемнәрен язып чык.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Япон кроссворды

Әлеге япон кроссвордында рәсем яшерелгән. Шул рәсемне ясау өчен сезгә өстәге саннар ярдәм итәчәк. Саннар рәттә ничә шакмак һәм нинди төс белән буялачагын күрсәтә. Ә монда нинди рәсем яшерелгән соң? Аны күрү өчен саннарны өстән аска таба укыйбыз.

Мәсәлән, беренче баганада 1, 2 һ.б. саннар бирелгән. Шулай булгач, калын кара сызыктан башлап 1 шакмакны зәңгәр төскә, 2 шакмакны акка буярга (дөресрәге буш калдырырга) кирәк. Шул рәвешле буташтырмыйча гына шакмакларны буясаң, матур гына рәсем килеп чыгар.

1	2	2	1	1	1	2	2	1	1	1	9	9	7	11	12	3	4	3	7	12	9	1
2	6	5	5	12	11	9	8	1	1	1	4	5	1	7	7	1	1	1	1	2	1	1
4	2	2	2	4	1	1	1	1	1	7	1	3	2	1	1	1	3	1	10	1	3	12
7	3	5	7	6	3	5	7	6	1	12	3	3	7	4	2	1	1	1	1	1	5	3
1	1	1	1	2	1	1	1	1	4	1	2	1	1	1	3	7	1	4	2	2	1	1
3	1	3	4	1	5	10	6	9	1	1	2	2	5	2	1	8	2	7	1	1	2	2
	4	1		1	1			4	11	2	1	1	2	1	1	2	10	2	4	1	2	1
	6	3		1	1			1	1		1	2	3				3	1		4	1	1
	1				1			3	1		4							2			1	
					2				2									1				

Төзеде Гүзәл СӘЕТОВА



1(166) — 2004

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТАТМЕДИА» МАССАКҮЛӘМ КОММУНИКАЦИЯ АГЕНТЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ

1990 елның март аеннан бирле чыга.

"САЛАВАТ КУПЕРЕ" ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ ЖУРНАЛ АГЕНТСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО МАССОВОЙ КОММУНИКАЦИИ «ТАТМЕДИА», ПРАВЛЕНИЯ СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ РТ И РЕДАКЦИИ.

Основан в 1990 году.

На татарском языке.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӘСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Диләра НӘҮРҮЗОВА рәсемнәре,

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.


«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе.

Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 21.01.2004 ел.
Басарга кул куелды 21.01.2004 ел.
Кәгазь форматы 60х100 1/8.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 12829 данә. Заказ Э-24.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



Песикәй һәм кышкы кошлар

Урамда да күптән кыш шул,
Кошлар кышын җим эзли.
Кем әйтә соң, кем белә:
Бу песикәй ни күзли?

Кошларга җим эзләшәме,
Әллә инде көнләшәме?
Үчләшмә син, песикәй!
Бар алып чык ипекәй!

Кошлар рәхмәт укырлар,
Сиңа да рәхәт булыр.
Әгәр тычкан тота алсаң,
Хуҗаң да рәхмәт укыр!

Кайт өеңә, песикәй?!
Алып чык син ипекәй!